**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2026 елның «09» июне** **2 9 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаишев муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Җир салымы турында»гы 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Лаишев муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаишев муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Җир салымы турында»гы 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктының «в» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «в) һава транспорты объектларын, аэродромнарны, аэропортларны (аэровокзалларны) һәм пассажирларны утырту һәм төшерү, аларга кирәкле хезмәт күрсәтү һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен кирәкле башка объектларны урнаштыру, шулай ук һава юлы белән күчерелә торган йөкләрне төяү, бушату һәм саклау өчен кирәкле объектларны урнаштыру өчен файдаланыла торган җир участокларына карата – 0,3 процент;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Лаишев муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаишев муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Олы Кабан авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Мөхәммәткулов